**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 14 декабре** **№__23__**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәрен билгеләү турында**

Җирләрне кирәгеннән артык ваклауны оптималь файдалану һәм төшереп калдыру, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү максатларында, шулай ук, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 13 мартындагы 85 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән гражданнарга арендага яисә милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт янындагы җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр,
- торак пункттан читтә (кыр җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 1,0 гектарга кадәр;

б) индивидуаль торак төзелеше өчен 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәре гражданнарга әлеге карарның үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәренең әлеге карарны кабул иткәнче гражданнарга аренда хокукларында бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алар тарафыннан сатып алына торган җир кишәрлекләренә кагылмавын билгеләргә.

5. Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, әлеге Карарның 2 пункты нигезендә яңа төзелә торган җир кишәрлекләре күләмнәренең иң чик күрсәткечләрен билгеләп, Җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль район Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**